**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ СОВЕТ**

422750, село Большая Атня, улица Советская, дом 38

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘТНӘ РАЙОН СОВЕТЫ**

422750, Олы Әтнә авылы, Совет урамы., 38нче йорт

Тел.: 8(84369)21004, факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

“14” август 2023 ел. №193

**Әтнә район Советының “Ышанычны югалту сәбәпле муниципаль вазыйфаларны биләүче затларны эштән азат итү (вазыйфаларыннан азат итү, вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату) тәртибен раслау турында”гы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, “Россия Федерациясе субъектларында иҗтимагый хакимиятне оештыруның гомуми принциплары турында” 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль закон, “Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” 2023 елның 13 июнендәге 258-ФЗ номерлы Федераль закон, “Ышаныч югалту сәбәпле эштән азат ителгән затлар реестры турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында”гы 2023 елның 12 июлендәге 1137 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең карары нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә район Советы карар итте:

1. Әтнә район Советының 04.08.2020 елгы 214 номеры карары белән расланган “Ышанычны югалту сәбәпле муниципаль вазыйфаларны биләүче затларны эштән азат итү (вазыйфаларыннан азат итү, вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату) тәртибе”нә, түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2 нче бүлекнең 1.1 пунктын “федераль законнар белән билгеләнгән очраклардан тыш” дип тулыландырырга;

2 нче бүлекнең 2.1 нче пунктында “яки белә торып дөрес булмаган яки тулы булмаган мәгълүматларны тәкъдим итү” сүзләрен, “федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, белә торып тулы булмаган мәгълүматларны тәкъдим итәргә, яки белә торып дөрес булмаган мәгълүматларны тәкъдим итәргә” дигән сүзләр белән алыштырырга;

2 нче бүлекнең 1.5 пунктын “федераль законнар белән билгеләнгән очраклардан тыш” дип тулыландырырга;

3 нче бүлекнең 2.1 пунктында “кешегә карата эштән азат итү (вазыйфасыннан азат итү) рәвешендә җәза куллану турында” сүзләрне “кешене эштән азат итү (вәкаләтләрен туктату) турында” сүзләр белән алыштырырга;

3 нче бүлекнең 2.4 пунктында:

беренче абзацта “коррупциячел хокук бозу кылган өчен ышанычны югалту сәбәпле эштән азат итү (вазыйфасыннан азат итү) рәвешендә җәза кулланылган кеше турында” сүзләрне “коррупциячел хокук бозу кылган өчен ышанычны югалту сәбәпле эштән азат итү (вәкаләтләрен туктату) турында” сүзләр белән алыштырырга;

а пунктчасында “эштән азат ителгән” сүзен “эштән азат ителгән (вәкаләтләре туктатылган)” сүзләре белән алыштырырга;

б пунктчасында “акт” сүзеннән соң “яки суд карары” сүзләре белән тулыландырырга, “эштән азат ителгән” сүзен “эштән азат ителгән (вәкаләтләре туктатылган)” сүзләре белән алыштырырга;

в пунктчасында “акт” сүзеннән соң “яки суд карары” сүзләре белән тулыландырырга, “эштән азат ителгән” сүзен “эштән азат ителгән (вәкаләтләре туктатылган)” сүзләре белән алыштырырга;

г пунктчасында “аңа карата эштән азат итү (вазыйфасыннан азат итү) рәвешендә җәза кулланылган” сүзләрен “вазыйфасыннан азат ителгән (вәкаләтләре туктатылган)” сүзләре белән алыштырырга;

3 нче бүлекнең 2.5 нче пунктында “Татарстан Республикасы Президенты” сүзләрен “Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)” сүзләре белән алыштырырга;

3 нче бүлекнең 2.6 нчы пунктында “нигез булган акт” сүзләрен “нигез булган акт яки суд карары” сүзләре белән алыштырырга;

3 нче бүлекнең 2.7 пунктын түбәндәге эчтәлектәге яңа редакциядә бәян итәргә:

“2.7 Бу тәртипнең 2.4. пунктының г пунктчасында каралган нигез буенча мәгълүматларны реестрдан чыгару өчен, коррупциячел хокук бозу өчен ышанычны югалту сәбәпле эштән азат ителгән (вәкаләтләре туктатылган) кешенең туганнары яки үз кешеләре, кеше бу вазифаны биләгән органга (оешмага) почта элемтәсе аша (гражданнарны шәхси кабул итүдә тапшырырга) үлем турында таныклыкның нотариаль рәвештә расланган күчермәсе кушымтасы белән язма гариза җибәрергә хокуклы.”

3 нче бүлекнең 2.8 пунктында:

“аңа карата эштән азат итү (вазыйфасыннан азат итү) рәвешендә җәза кулланылган” сүзләрен “вазыйфасыннан азат ителгән (вәкаләтләре туктатылган)” сүзләре белән алыштырырга;

“Татарстан Республикасы Президенты” сүзләрен “Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)” сүзләре белән алыштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Әтнә муниципаль районы башлыгы-
Әтнә район Советы рәисе: Г.Г.Хәкимов